ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 337 от «12» 09 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен 5 (биш) ел һәм күчемле мөлкәт өчен 3 (өч) ел тәшкил итә.

2. Сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер мәртәбә яисә өлешләп түләү), шулай ук арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшкуарлык субъектының әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә өлешләп түләү срогын сайлау хокукына ия.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (prav.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.М. Никифоров

0000012356